МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.03.2022 г.Казань № 194

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 4 апрелендә 9007 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе үрнәген (аларга бирелгән җаваплар тикшерелә торган зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеген) раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законның 53 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерык кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе үрнәген (аларга бирелгән җаваплар тикшерелә торган зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеген) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2022 елның 17
мартындагы 194 номерлы
боерыгы белән расланды

Үрнәк

| |
|---|
| Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрольлек (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 16 апрелендәге 604 санлы карарында каралган QR-код |

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе үрнәге (аларга бирелгән җаваплар тикшерелә торган зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге)

1. Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төре: Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).

2. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының исеме: Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

3. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү формасы: ______________________________.

4. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның атамасы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ______________________________

5. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның яки шәхси эшкуарның ИНН һәм (яки) ОГРН ______________________________

6. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның юридик адресы яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы ______________________

7. Үзенә карата тикшерүдә тоту (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты: ______________________________

8. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары): ______________________________.

9. Тикшерү битен тутыру датасы: ______________________________.

10. Контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында 20___ елның ___________ № _____ боерык (карар) белешмәләре.

11. Контроль (күзәтчелек) чарасының хисап номеры: _______________.

12. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүче һәм тикшерү кәгазен тутыручы вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары:

_______________________________________________________________________________.

13. Тикшерүдә тотыла торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү яки үтәмәүне раслый торган контроль сораулар исемлеге:

| Т/с | Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотыла торган зат тарафыннан зарури таләпләренең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт | Җавап төрләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Кулланып булмый | Искәрмә |
| 1. | Дәүләтнеке булмаган (коммерция яки коммерциясез) оешманың яки шәхси эшкуарның медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе бармы? | «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы | | | | |
| 2. | Дәүләтнеке булмаган (коммерция яки коммерциясез) оешманың яки шәхси эшкуарның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе бармы (бу төр хезмәтләр күрсәтелгән очракта)? | «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы | | | | |
| 3. | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган һөнәри стандартларга туры китереп дәүләтнеке булмаган (коммерцияле һәм коммерциясез) оешманың яки шәхси эшкуарның хезмәткәрләренең вазыйфаи күрсәтмәләре эшләнгәнме? | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының 1998 елның 21 августындагы 37 номерлы карары белән расланган Җитәкчеләр, белгечләр һәм башка хезмәткәрләрнең вазыйфалары буенча квалификация белешмәлеге, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының «Социаль эш буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 351н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәткәр» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 354н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль өлкәдә тернәкләндерү эше буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 352н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль өлкәдә психолог» һөнәри стандартын раслау турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 682н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Гаилә белән эшләү буенча белгеч» һөнәри стандартын | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | расլау турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 683н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәгариф өлкәсендә психолог» һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 24 июлендәге 514н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 12 гыйнварындагы 2н номерлы «Кече медицина персоналы» һөнәри стандартын раслау турында» боерыгы | | | | |
| 4. | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү турында килешү бармы? | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 24[7] статьясы | | | | |
| 5. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның шәхси әйберләрен һәм кыйммәтләрен саклау тәэмин ителәме? | «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 12 пункты | | | | |
| 6. | Дезинфекция камерасында эшләүчеләрнең урын-жир кирәк-яраклары (матрацлар, мендәрләр, юрганнар) пычрануга карап, эпидемия күрсәткечләре буенча, шулай ук яшәүчеләрне чыгарганнан соң (алар вафат булгач) эшкәртелүгә дучар ителәме? | Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 24 декабрендәге 44 номерлы карары белән расланган «Урыннарны, биналарны, корылмаларны, җиһазларны һәм транспортны эксплуатацияләүгә, шулай ук товарлар сатуны, эшләр башкаруны яисә хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектлары эшчәнлеге шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.1.3678-20 таләпләренең 9.47 пункты | | | | |
| 7. | Дәүләтнеке булмаган (коммерция яки коммерциясез) оешманың яки шәхси эшкуарның барлык хезмәткәрләрендә белем, квалификация һәм һөнәри әзерлек дәрәҗәсе биләгән вазыйфаларына туры киләме? | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының 1998 елның 21 августындагы 37 номерлы карары белән расланган Җитәкчеләр, белгечләр һәм башка хезмәткәрләрнең вазыйфалары буенча квалификация белешмәлеге, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының «Социаль эш буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 351н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәткәр» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 354н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль өлкәдә тернәкләндерү эше буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2020 елның 18 июнендәге 352н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль өлкәдә психолог» һөнәри стандартын раслау | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 682н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Гаилә белән эшләү буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 683н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәгариф өлкәсендә психолог» һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 24 июлендәге 514н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү педагогы» һөнәри стандартын раслау турында» 2018 елның 5 маендагы 298н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 12 гыйнварындагы 2н номерлы «Кече медицина персоналы» һөнәри стандартын раслау турында» боерыгы | | | | |
| 8. | Балигъ булмаганнарга хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган (коммерция яки коммерциясез) оешма белгечләренең яки шәхси эшкуарның хөкем ителмәгәнлеге турында белешмәләре бармы? | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясы | | | | |
| 9. | Дәүләтнеке булмаган (коммерцияле яки коммерциясез) оешма яки шәхси эшкуар биналарында аларның тормыш-көнкүрешен чикләүне исәпкә алып, инвалидлар һәм башка затлар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге тулысынча тәэмин ителгәнме? | «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы белән расланган Тиешле ярдәм күрсәтү объектларыннан һәм халыкка хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү тәртибенең 4 пункты | | | | |
| 10. | Дәүләтнеке булмаган (коммерцияле яки коммерциясез) оешма яки шәхси эшкуар эшчәнлеге турында мәгълүматның «Интернет» челтәренең рәсми сайтында һәм оешманың мәгълүмат стендларында ачыклыгы һәм һәркем өчен мөмкин булуы тәэмин ителгәнме? | «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясы | | | | |
| 11. | Дәүләтнеке булмаган (коммерцияле һәм | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | коммерциясез) оешма яки шәхси эшкуар биналары санитар-гигиена нормаларына һәм таләпләренә җавап бирәме? | декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.2 пункты | | | | |
| 12. | Социаль хезмәтләрдән файдаланучылардан социаль хезмәтләр өчен түләве дөрес исәпләнәме һәм алынамы? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәтләрне бушлай күрсәтү өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемне билгеләү кагыйдәләрен билгеләү турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Социаль хезмәтләрне бушлай күрсәтү өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемне билгеләү кагыйдәләре | | | | |
| 13. | Социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче тарафыннан йөкләмәләре үтәләме? | «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы | | | | |
| 14. | Социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче тарафыннан социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның хокуклары сакланамы? | «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы | | | | |

| | | |
|---|---|---|
| Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүче һәм тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары | ________________ (имза) | ________________ (дата) |
| Социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче затның тикшерү кәгазе тутырганда катнашкан вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары | ________________ (имза) | ________________ (дата) |